СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 103 от 15.12.2021

на № __от _________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренә наем шартнамәләре буенча торак урыннар өчен түләү чыгымнарын каплауга компенсация түләүләре бирү тәртибен раслау турында

Мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренә ярдәм итү максатыннан, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 74.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренә наем шартнамәләре буенча торак урыннар өчен түләү чыгымнарын каплауга компенсация түләүләре бирү тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына ел саен әлеге карарда каралган йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итүгә финанс чаралары бүлеп бирүне күздә тотырга.

3. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru. рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы                                                  Р.Н.Минниханов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 15 декабрендәге 103 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренә наем шартнамәләре буенча торак урыннар өчен түләү чыгымнарын каплауга компенсация түләүләре бирү тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр.

**1.1.** Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренә наем шартнамәләре буенча торак урыннар өчен түләү чыгымнарын каплауга компенсация түләүләре бирү тәртибен һәм шартларын билгели (алга таба - компенсация түләүләре).

**1.2.** Компенсация түләүләре учреждение хезмәткәрләренә әлеге максатларга бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җирле бюджетның җыелма бюджет язмасы нигезендә бирелә.

**1.3.** Әлеге Тәртип нигезендә компенсация түләүләре Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренең түбәндәге категорияләренә бирелә:

1.3.1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы мәгариф учреждениеләренең педагогик хезмәткәрләренә;

1.3.2. мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренә.

**1.4.** Гражданнарда компенсация түләүләренә хокук түбәндәге шартлар булганда барлыкка килә:

– Саба муниципаль районы Башкарма комитеты белән торак урыннары буенча наем шартнамәләре төзегән гражданнар;

– гражданнар Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләре белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торалар;

– Хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының Саба муниципаль районы муниципаль берәмлеге чикләрендә урнашкан торак урыннарына хезмәт эшчәнлеген башкару урыны буенча теркәлгән милек хокукы булмау. Гаилә әгъзаларына ир, хатын, балалар керә.

– гражданнарның наем өчен түләү ставкасы 1 кв.м өчен 50 сумнан артык тәшкил итә.

**1.5.** Компенсация түләүләренә торак урыныннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) кертелә.

**1.6.** Компенсация түләүләренә түбәндәгеләр кертелми:

– торак урынны карап торткан һәм ремонтлаган өчен түләү (күпфатирлы йорт белән идарә итү, күпфатирлы йортта гомуми милекне тоту, агымдагы һәм капиталь ремонтлау буенча хезмәт күрсәтүләр һәм эшләр);

– коммуналь хезмәтләр өчен түләү (салкын һәм кайнар су белән тәэмин итү, электр белән тәэмин итү, газ белән тәэмин итү, җылылык, чүп-чарны чыгару);

– телефон, домофон, лифт өчен түләү.

## 2. Компенсация түләүләре күләме.

**2.1.** Наем шартнамәләре буенча торак урыннар өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү наем өчен түләү суммасының 50% ын тәшкил итә.

## 3. Учреждение хезмәткәрләренә компенсация түләүләре бирү өчен кирәкле документлар исемлеге.

**3.1.** Компенсация түләүләрен алу өчен гражданнар эш бирүчегә (алга таба текст буенча - "Учреждение") түбәндәге документларны тапшыралар:

3.1.1. Наем шартнамәләре буенча торак урыннар өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү турында Учреждение җитәкчесе исеменә гариза;

3.1.2. Гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының (иренең, хатынының, балаларының) хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы чикләрендә урнашкан торак урыннарга теркәлгән милек хокуклары юклыгын раслый торган документларның күчермәләре;

3.1.3. Гаилә составы турындагы белешмә;

3.1.4. Социаль ярдәм чараларының торак урыннан файдаланган өчен түләүгә бәйле рәвештә алынмавы турында социаль яклау органыннан белешмә;

3.1.5. Граждан белән наемга алучы арасында торак урын яллау шартнамәсе;

3.1.6. Программада катнашучының һәм аның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы документларның күчермәләре (паспорты яисә аны алмаштыручы башка документ);

3.1.7. Гражданның наем өчен түләвен раслаучы документлар.

**3.2.** Учреждение хезмәткәре тәкъдим ителгән документлардагы белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплы.

**3.3.** Документларны тикшерү учреждение җитәкчесе тарафыннан гаризаларны журналда теркәгән көннән соң 10 эш көне эчендә башкарыла.

**3.4.** Дәгъвачыга компенсация түләүләрен түләүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

– әлеге Тәртипнең 3.2 пунктында санап кителгән документларның булмавы;

– гражданның әлеге Тәртипнең 1.3.һәм 1.4 пунктларында каралган таләпләргә һәм шартларга туры килмәве.

– тапшырылган документларның яисә алардагы белешмәләрнең дөрес булмавы;

– агымдагы финанс елында күрсәтелгән чыгымнарны финанслауга җирле бюджет акчалары булмау.

**3.5.** Учреждение җитәкчесе оешма хезмәткәрләренә, карар кабул ителгәннән соң 5 эш көне эчендә компенсация түләүләрен бирүдән баш тарту турында язма рәвештә хәбәр итә.

**3.6.** Компенсация түләүләрен бирү турындагы карар Учреждение җитәкчесе боерыгы белән рәсмиләштерелә.

## 4. Учреждение хезмәткәрләренә компенсация түләүләре бирү механизмы

**4.1.** Учреждение хезмәткәрләренә компенсация түләүләре әлеге түләүләрне башкару өчен җирле бюджетта каралган акчалар хисабына һәм чикләрендә башкарыла.

**4.2.** Учреждение хезмәткәрләренә компенсация түләүләре ел саен Учреждение хезмәткәре гаризасы буенча бирелә.

**4.3.** Саба муниципаль районы Финанс-бюджет палатасының Үзәкләштерелгән бухгалтериясе квартал саен торак яллануга бәйле рәвештә учреждение хезмәткәрләренә чыгымнарны компенсацияләү буенча түләүләрне гамәлгә ашыра.

**4.4.** Түләүләр банк оешмаларында ачылган гражданның исәп-хисап счетына күчерү рәвешендә башкарыла.

**4.5.** Компенсация түләүләре торак урын яллана башлаган датадан, яки оешма хезмәткәренең шәхси гаризасы буенча, торак урынны наемга алган өчен компенсация сораган датаны күрсәтеп, соңрак сроктан бирелә.

**4.6.** Компенсация күләме торак урынны наемга алу турындагы килешүдә каралган суммадан артык була алмый.

**4.7.** Яшәү урыны үзгәргән очракта, учреждение хезмәткәре 3 (өч) эш көне дәвамында бу хакта учреждение җитәкчесенә хәбәр итәргә һәм раслаучы документларны тапшырырга тиеш.

## 5. Компенсация түләүләрен бирүне туктату.

**5.1.** Учреждение хезмәткәрләренә компенсация түләүләре бирү түбәндәге очракларда туктатыла:

- Учреждение белән хезмәт шартнамәсен өзү;
- торак урынын наем шартнамәсен туктату яисә вакытыннан алда өзү;
- Килешүдә күрсәтелгән адрес буенча учреждение хезмәткәре яшәмәү фактларын ачыклау;
- Әлеге Тәртипнең 1.3. һәм 1.4 пунктларында каралган нигезләрне төшереп калдыру.

## 6. Акчаларны тотуны тикшереп тору.

**6.1.** Саба муниципаль районы бюджеты акчаларыннан максатчан файдалануны Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә бюджет акчалары бүлүчеләр һәм вәкаләтле органнар тикшереп тора.